ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

**« 30 » декабрь 2016 ел** **№ 1381**

**Арча муниципаль районында социаль хезмәтләр күрсәтүче муниципаль учреждениеләрнең эш сыйфатын бәяләүнең бәйсез системасын булдыру турында**

Арча муниципаль районында социаль хезмәт күрсәтүләрнең сыйфатын күтәрү максатларында “Мәдәният, социаль хезмәт күрсәтү, сәламәтлекне саклау һәм мәгариф өлкәсендә оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтүнең сыйфатын бәйсез бәяләүне уздыру мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” 2014 елның 21 июлендәге 256 номерлы Федераль закон нигезендә карар бирәм:

1. Арча муниципаль районында күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфатын бәйсез бәяләү критерийларын 1 нче кушымта нигезендә расларга:

- белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның белем бирү эшчәнлеге сыйфатын бәяләү күрсәткечләре;

- мәдәният оешмаларының хезмәт күрсәтүләре сыйфатын бәяләүнең гомуми критерийларын характерлаучы күрсәткечләр;

- яшьләр сәясәте, физик культура һәм спорт оешмаларының хезмәт күрсәтүләре сыйфатын бәяләүнең гомуми критерийларын характерлаучы күрсәткечләр.

2. Арча МР башкарма комитетының «Мәгариф идарәсе» МУ (Дәүләтбаев З.М.), Арча МР башкарма комитетының «Мәдәният идарәсе» МУ (Мөхетдинов Р.Р), Арча МР башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге (Габделгазиз И.Н.) эшчәнлеге юнәлешләре буенча муниципаль учреждениеләрнең эш сыйфатын бәйсез бәяләүне оештыру буенча вәкаләтләрне йокләргә.

Арча МР башкарма комитетының «Мәгариф идарәсе» МУ (Дәүләтбаев З.М.), Арча МР башкарма комитетының «Мәдәният идарәсе» МУ (Мөхетдинов

Р.Р.), Арча МР башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туристлык бүлегенә (Габделгазизов И.И.) түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

3.1. Әлеге карар белән җайга салына торган мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Иҗтимагый советы белән 1.112017 елга кадәр хезмәттәшлек;

3.2. Әлеге карар белән расланган муниципаль учреждениеләр, мәгариф, мәдәният, яшьләр сәясәте, физик культура һәм спорт эшчәнлеген бәяләү критерийлары исемлеге нигезендә үтәлә торган муниципаль учреждениеләрнең эш сыйфатын бәяләгәндә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иҗтимагый советы тәкъдимнәреннән файдалану;

3.3. Социаль хезмәтләр күрсәтүче ведомство буйсынуындагы учреждениеләрнең эш сыйфатын бәйсез бәяләүне формалаштыру буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иҗтимагый советының эшчәнлеге турында ел саен (1 февральгә кадәр) "Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге" Дәүләт бюджет учреждениесенә гомумиләштерү өчен Арча муниципаль районы башкарма комитетының икътисад һәм финанслар бүлегенә мәгълүмат бирү.

4. «Арча муниципаль районында социаль хезмәтләр күрсәтүче учреждениеләрнең эш сыйфатын бәяләүнең бәйсез системасын булдыру турында» Арча муниципаль районы башкарма комитетының 2014 елның 06 маендагы 460 номерлы карарының үз көчен югалтуын танырга

5. Карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru/) Интернет» челтәрендә урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.И.Гарифҗановка йөкләргә.

Җитәкче И.О.Галимуллин

Башкарма комитет җитәкчесенең
30.12. 2016 ел. №1321 карарына

1 нче кушымта

**Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның белем бирү эшчәнлеге сыйфатын бәяләү күрсәткечләре**

| № т/б | күрсәткечләр | Үлчәү берәмлеге (күрсәткечләрнең әһәмияте) |
|---|---|---|
| | **1.Мәгълүматның ачыклыгы һәм һәркем файдалана алырлык булуы - 30 балл** | |
| 1.1. | белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешма турында мәгълүматның тулылыгы һәм актуальлеге, һәм аның эшчәнлеге, оешманың рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Интернет челтәрендәге рәсми сайтта урнашуы; | Балл (0 дән алып до10) |
| 1.2. | оешманың рәсми сайтында оешманың педагогик хезмәткәрләре турында мәгълүматлар булу | Балл (0 дән 5 кә кадәр) |
| 1.3. | Интернет челтәрендәге оешманың рәсми сайтында күрсәтелә торган электрон серверлар ярдәмендә, шул исәптән оешма эшен яхшыртуга юнәлдерелгән тәкъдимнәр кертү мөмкинлеге булу, мәгариф хезмәтләрен алучы белән телефон аша, электрон почта аша хезмәттәшлекнең һәркем файдалана алырлык булуы | Балл (0 дән алып до10) |
| 1.4. | оешмаларга мәгариф хезмәтләре алучылардан кергән гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау барышы турында белешмәләр алу мөмкинлеге булу (телефон буенча, электрон почта аша, оешманың рәсми сайтында һәркем файдалана алырлык электрон сервислар ярдәмендә) | Балл (0 до5) |
| | **2. Шартларның уңайлы булуы - 70 балл** | |
| 2.1. | оешманы матди - техник һәм мәгълүмати тәэмин итү | Балл (0 дән алып до10) |
| 2.2. | сәламәтлекне саклау һәм ныгыту өчен шартлар булу, укучыларның туклануын оештыру | Балл (0 дән алып до10) |
| 2.3. | Укучылар белән индивидуаль эшләү өчен шартлар | Балл (0 дән алып до10) |
| 2.4. | өстәмә белем бирү программалары булу | Балл (0 дән алып |

| | | |
|---|---|---|
| | | до10) |
| 2.5. | Аларның конкурсларда һәм олимпиадаларда (шул исәптән ботенроссия һәм халыкара), күргәзмәләрдә, смотрларда, физкультура чараларында, спорт чараларында, шул исәптән рәсми спорт ярышларында һәм башка массакүләм чараларда катнашуларын да кертеп, укучыларның иҗади сәләтләрен һәм мәнфәгатьләрен үстерү мөмкинлекләре булу | Балл (0 дән алып до10) |
| 2.6. | Укучыларга психолог - педагог, медицина һәм социаль ярдәм күрсәтү мөмкинлеге булу | Балл (0 дән алып до10) |
| 2.7. | сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән укучыларны һәм инвалидларны укытуны һәм тәрбияләүне оештыру шартлары булу | Балл (0 дән алып до10) |

**3. Хезмәткәрләрнең игътибарлылыгы, ихтирамлылыгы һәм компетентлыгы - 20 балл**

| | | |
|---|---|---|
| 3.1. | мәгариф хезмәтләрен алучыларның мәгариф хезмәтен алучыларның гомуми саныннан оешмалар хезмәткәрләренең рәхимлелеген һәм ихтирамлыгын уңай бәяли торган өлеше | Балл (0 дән алып до10) |
| 3.2. | мәгариф хезмәтләрен алучыларның оешмалар хезмәткәрләренең компетентлыгы белән канәгать калган, сораштырылган мәгариф хезмәтләрен алучыларның гомуми саныннан өлеше | Балл (0 дән алып до10) |

**4.Хезмәтләр күрсәтүнең сыйфаты белән канәгатьлек - 30 балл**

| | | |
|---|---|---|
| 4.1. | белем бирү хезмәтләрен алучыларның оешманы матди яктан - техник яктан тәэмин итү белән канәгатьләндерелгән өлеше, сораштырылган мәгариф хезмәтләрен алучыларның гомуми саныннан | Балл (0 дән алып до10) |
| 4.2. | күрсәтелә торган мәгариф хезмәтләрен алучыларның сыйфатыннан канәгать калган өлеше. Белем бирү хезмәтләрен алучыларның гомуми саныннан | Балл (0 дән алып до10) |
| 4.3. | мәгариф хезмәтләрен алучыларның мәгариф хезмәтләрен алучыларның гомуми саныннан туганнарына һәм танышларына оештыруны тәкъдим итәргә әзер булган өлеше | Балл (0 дән алып до10) |
| | **БАРЛЫГЫ** | **150 балл** |

**Мәдәният оешмаларының хезмәт күрсәтүләре сыйфатын бәяләүнең гомуми критерийларын характерлаучы күрсәткечләр**

| № т/б | Күрсәткеч | Үлчәү берәмлеге (күрсәткечнең әһәмияте) |
|---|---|---|

**1. Мәгълүматның ачыклыгы һәм һәркем файдалана алырлык булуы - 35 балл**

| | | |
|---|---|---|
| 1.1. | мәдәният оешмасының тулы һәм кыскартылган исеме, урнашу урыны, почта адресы, юл йөрү схемасы, электрон почта адресы, мәдәният оешмасы структурасы, гамәлгә куючылар (гамәлгә куючылар) турында белешмәләр, гамәлгә кую документлары | 0 дән 4 баллга кадәр |
| 1.2. | күрсәтелә торган хезмәтләргә карата таләпләр (стандартлар, регламентлар, күрсәтелә торган хезмәтләрне тасвирлау), мәдәниятне оештыруны матди-техник тәэмин итү | 0 дән 5 баллга кадәр |
| 1.3. | дәүләт яисә муниципаль биремне үтәү турында мәгълүмат, мәдәният оешмасы эшчәнлеге нәтиҗәләре турында хисап | 0 дән 7 баллга кадәр |
| 1.4. | Мәдәниятне оештыру күргәзмәләре һәм экспозицияләре турында мәгълүмат җиткерү. Мәдәниятне оештыру буенча виртуаль экскурсияләр | 0 дән 7 баллга кадәр |
| 1.5. | алда торган тамашалар һәм куелышлар турында мәгълүмат бирү | 0 дән 7 баллга кадәр |
| 1.6. | яңа чаралар турында мәгълүмат бирү | 0 дән 5 баллга кадәр |

**2. Шартларның уңайлы булуы - 32 балл**

| | | |
|---|---|---|
| 2.1. | мәдәният оешмасында булу уңайлылыгы дәрәҗәсе (утыру урыны, гардероб, бүлмәләрнең чисталыгы һәм башкалар) | 0 дән 5 баллга кадәр |
| 2.2 | мәдәният оешмасы тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләр исемлеге. Хезмәтләр ассортименты буенча чикләүләр, хезмәтләрне кулланучылар буенча чикләүләр. Мәдәният оешмалары тарафыннан күрсәтелә торган өстәмә хезмәтләр. Түләүле нигездә бирелә торган хезмәтләр аларның бәясе. Тапшламалар бирү шартлары | 0 дән 5 баллга кадәр |
| 2.3. | мәдәниятне оештыруның өстәмә хезмәтләре булу (җәмгать туклануы урыннары, интерактив уеннар, театр, чаралар, аудиогид һәм башкалар) | 0 дән 5 баллга кадәр |
| 2.4. | хезмәт күрсәтүләрнең бәясе (күрсәтелә торган хезмәтләргә бәянең һәркем файдалана алырлык булуы, аның хезмәт сыйфатына туры килүе) | 0 дән 5 баллга кадәр |
| 2.5. | өстәмә хезмәтләр бәясе (ксерокопирование, башка китапханәләргә китап заказы, кирәкле китапны кире кайтару турында мәгълүмат бирү, китапны кичектерү мөмкинлеге, хезмәт сыйфатының туры килүе) | 0 дән 7 баллга кадәр |
| 2.6. | иминлекне тәэмин итү (саклау, медицина ярдәме, иминлек | 0 дән 5 баллга |

| | | |
|---|---|---|
| | техникасы, яклау чаралары) | кадәр |

**3.Хезмәтләр алганда чиратта көтү вакыты - 27 балл**

| | | |
|---|---|---|
| 3.1. | Мәдәният оешмасының электрон билеты/билетларны броньлау мөмкинлеге/электрон чираты | 0 дән 5 баллга кадәр |
| 3.2. | Мәдәният оешмасының транспорт һәм җәяү барып җитүе | 0 дән 5 баллга кадәр |
| 3.3. | Мәдәният оешмасының эш графигы уңайлы | 0 дән 5 баллга кадәр |
| 3.4. | Билетларны сатып алу (броньлау) процедурасы уңайлырак | 0 дән 5 баллга кадәр |
| 3.5. | керәкле басманың гадилеге/уңайлылыгы | 0 дән 7 баллга кадәр |
| 4.1. | мәдәният оешмасы персоналының ягымлылыгы, әдәплелеге һәм компетентлыгы; | 0 дән 5 баллга кадәр |
| 4.2. | фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре, мәдәният оешмасының, аның структур бүлекчәләре һәм филиалларының (алар булса), эш режимы, эш графигы; контактлы телефоннар, электрон почта адреслары, оешма хезмәтләренең сыйфатын яхшырту буенча тәкъдимнәр җибәрү өчен бүлек | 0 дән 5 баллга кадәр |
| 5.1. | түләем алганда мәдәният оешмасы хезмәтләрен күрсәтү сыйфатыннан канәгатьлек дәрәҗәсе; | 0 дән 10 баллга кадәр |
| 5.2. | вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан расланган оешмалар эшенең нәтиҗәлелегенең билгеле бер критерийлары нигезендә оешманың эш сыйфатын бәяләү тәртибе; мәдәният оешмаларының хезмәт күрсәтүләре сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләре, шулай ук аларның эшчәнлек сыйфатын яхшырту турындагы тәкъдимнәр; оешма эшенең сыйфатын яхшырту планы; | 0 дән 6 баллга кадәр |
| 5.3. | экскурсия уздыру сыйфаты; | 0 дән 8 баллга кадәр |
| 5.4. | мәдәният оешмасы экспозицияләренең төрлелеге; | 0 дән 8 баллга кадәр |
| 5.5. | мәдәният оешмасының репертуары төрлелеге; | 0 дән 8 баллга кадәр |
| 5.6. | матди яктан - мәдәният оешмасын техник яктан тәэмин итү; | 0 дән 6 баллга кадәр |

| | | |
|---|---|---|
| 5.7. | ихтыяж булган әдәбият булу; | 0 дән 7 баллга кадәр |
| 5.8. | иҗат төркемнәренең, кызыксынулар буенча түгәрәкләрнең төрлелеге; | 0 дән 6 баллга кадәр |
| 5.9. | мәдәни - массакүләм чаралар уздыру сыйфаты | 0 дән 6 баллга кадәр |
| | **БАРЛЫГЫ** | **169 балл** |

**Яшьләр сәясәте оешмалары, физкультура һәм спорт хезмәтләренең сыйфатын бәяләүнең гомуми критерийларын характерлаучы күрсәткечләр**

| № т/б | күрсәткечләр | Үлчәү берәмлеге (күрсәткечләрнең әһәмияте) |
|---|---|---|
| | **1.Мәгълүматның ачыклыгы һәм һәркем файдалана алырлык булуы - 40 балл** | |
| 1.1 | оешмалар күрсәткән хезмәт күрсәтүләр сыйфатына хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучыларның нигезле шикаятьләре саны | 0 дән 10 баллга кадәр |
| 1.2. | травматизмның теркәлгән очраклары саны | 0 до10 баллдан |
| 1.3. | 1 яки югары квалификация категориясе булган укытучылар һәм инструментлар штат тренерлары өлеше, штат тренерларының гомуми саныннан - укытучылар һәм инструментлардан | 0 дән 10 баллга кадәр |
| 1.4. | учреждениене матди яктан - техник яктан тәэмин итүгә тотылган акчалар өлеше, спорт мәктәбен тотуга гомуми чыгымнардан | 0 дән 10 баллга кадәр |
| 2.1. | оешманы матди - техник һәм мәгълүмати тәэмин итү | 0 дән 10 баллга кадәр |
| 2.2. | оешмада булу уңайлылыгы дәрәҗәсе (утыру урыны, гардероб, бүлмәләрнең чисталыгы) | 0 дән 10 баллга кадәр |
| 2.3. | Укучылар белән индивидуаль эшләү өчен шартлар | 0 дән 10 баллга кадәр |

| | | |
|---|---|---|
| 2.4. | хезмәт күрсәтүләрнең бәясе (күрсәтелә торган хезмәтләргә бәянең һәркем файдалана алырлык булуы, аның хезмәт сыйфатына туры килүе) | 0 дән 10 баллга кадәр |

1. **Хезмәтне алганда чиратта көтү вакыты - 20 балл**

| | | |
|---|---|---|
| 3.1. | оешманың транспорт һәм җәяү барып житүе | 0 дән 10 баллга кадәр |
| 3.2. | Оешманың эш графигы уңайлырак | 0 дән 10 баллга кадәр |

1. **Хезмәткәрләрнең игътибарлылыгы, ихтирамлылыгы һәм компетентлыгы - 10 балл**

| | | |
|---|---|---|
| 4.1. | оешманың персоналының яхшылыгы, әдәплелеге һәм компетентлыгы | 0 дән 10 баллга кадәр |

**5. Хезмәтләр күрсәтүнең сыйфатына ирешү - 20 балл**

хезмәтләр күрсәтүнең нәтиҗәлелеге (ахыргы нәтиҗәсе):

| | | |
|---|---|---|
| 5.1. | контингентның саклануы | 0 дән 10 баллга кадәр |
| 5.2. | спорт разряды алган укучылар, тәрбияләнүчеләр өлеше, спорт дәрәҗәсе. | 0 дән 10 баллга кадәр |
| | **БАРЛЫГЫ** | 130 балл |